# БУЛАЧАК УКЫТУЧЫЛАРНЫ МӨСТӘКЫЙЛЬ ЭШЛӘРГӘ ӨЙРӘТҮ

**Римма ШӘМСЕТДИНОВА, КФУның Тарих институты составындагы Россия тарихы һәм укыту методикасы кафедрасы доценты, тарих фәннәре кандидаты**

Булачак тарих укытучыларын әзерләү барышында аларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтү әһәмияткә ия. Шул уңайдан, Россия тарихы һәм укыту методикасы кафедрасында студентларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтүнең эзлекле системасы булдырылды. Бу система студентларның семинарларга һәм практик дәресләргә, зачетларга һәм имтиханнарга ныклы әзерлеген тәэмин итү белән бергә, беренче чыганаклар (Россия тарихының төрле чорларына караган мемуар әдәбият, монографияләр, шулай ук тарих фәненә караган журналлар) белән эшли белүен дә күздә тота. Ә инде тарих белән бергә инглиз телен дә өйрәнүче студентларга Россия тарихы буенча инглиз телендәге басмалар белән дә танышып барырга киңәш итәбез. Моннан тыш, студентлар алдына аерым предметлар буенча, Казан музейлары һәм архивлары материалларын файдаланып, иҗади эшләр башкару бурычы да куела. Болар барысы да булачак педагогларның үз белгечлекләрен ныклап үзләштерүенә ирешү өчен эшләнә.

Ике баскычлы укытуга күчү һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2011 елның 17 гыйнварында расланган югары һөнәри белем бирү системасында Федераль дәүләт стандартларының гамәлгә керүе бездән студентларның мөстәкыйль эшләвен оештыруның формаларын һәм алымнарын яңача үзгәртеп коруны таләп итә.

Бакалаврлар әзерләү программаларын гамәлгә ашыру шартларына куела торган таләпләр нигезендә, лекцияләрнең күләме аудитория дәресләренең 40 процентыннан артмаска тиеш. Димәк, белем бирүнең авырлык үзәге лекцияләр укудан студентларның мөстәкыйль эшчәнлеге ягына күчә дигән сүз. Аудиториядә үткәрелә торган дәресләр белән аудиториядән тыш эш пропорциясенең үзгәрүе студентларның мөстәкыйль эшен оештыру проблемасын аерым фәннәрнең (дисциплиналарның) традицион чикләрендә генә түгел, ә тулаем хәл итү бурычын куя. Шул ук вакытта бакалаврлар әзерләү буенча төп белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләре стандартларда каралган таләпләрдән чыгып ясала. Ә бу үз чиратында «мәгълүматларны туплауның, саклауның, эшкәртүнең төп алымнарын һәм ысулларын файдалануга», шулай ук «системалаштырылган теоретик һәм практик белемнәрне мәгариф өлкәсендәге фәнни-тикшерену бурычларын билгеләүгә һәм тормышка ашыруга» әзер булуны күздә тота.

Әлеге проблеманы уңышлы тормышка ашыру занятиеләрне үткәрүнең интерактив формаларын киң куллануны таләп итә. Шуның белән бергә интерактив формаларда үткәрелә торган дәресләрнең күләме аудиториядә үткәрелә торган дәресләрнең кимендә 20 процентын тәшкил итәргә тиеш. Бу исә укытучыдан үзе үткәрә торган дәресләрнең методларын камилләштерү белән бергә, студентларны аларга әзерләү процессына тиешле яңалыклар кертүне дә таләп итә.



Студентларның аудиториядән тыш эшенә килгәндә, безнең карашка, аны оештыруның гамәлдәге системасыннан бөтенләй баш тарту кирәк түгелдер. Биредә аны яңача оештыруның ике төп юнәлешен билгеләү зарур.

Беренчедән, бу эшнең чагыштырма күләме артуы һәм бакалаврлар әзерләү буенча төп программаларны үзләштерүдә роле үсүе тиешле методик басмалар һәм электрон ресурслар таләп итә.

Икенчедән, аудиториядән тыш эшне оештыру кафедрада билгеләнгән предметлар буенча эшләнелә торган электрон ресурслар кысаларында алып барылырга тиеш. Бу укытучы тарафыннан методик җитәкчелекне һәм контрольне системалырак һәм тизрәк хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк. Бу уңайдан шуны да искәртеп үтү артык булмас: стандартларда «мәгълүматлар белән идарә итү чарасы буларак, компьютер белән эшләргә әзер булу» таләбе дә куела.

Россия тарихы һәм укыту методикасы кафедрасы галимнәре һәм укытучылары теоретик һәм методик яктан әзерлекле генә түгел, иҗади фикерләүче, хәзерге мәктәп шартларында белем бирүнең база һәм электив курслары программаларын эшләргә һәм уңышлы рәвештә тормышка ашырырга әзер булган педагоглар әзерләүне үзләренең изге бурычлары дип саныйлар һәм шул юнәлештә максатчан эш алып баралар.